ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ г. Казань Боерык

12.04.2022 № 84 - од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 ел, 345-од номерлы боерыгы белән расланган, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга рөхсәт ителүе турында белдерү кәгазен җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максаты белән боерам:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 ел, 345-од номерлы боерыгы белән расланган, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга рөхсәт ителүе турында белдерү кәгазен җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 04.06.2021 ел 163-од номерлы, 31.08.2021 ел 255-од номерлы, 28.09.2021 ел 293-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне истә тотып).

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип танырга.

Рәис Ф.С.Батков

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының
11.11.2020 ел, 345-од
номерлы боерыгы белән
расланган (Татарстан
Республикасы Биологик
ресурслар буенча дәүләт
комитетының 12.04.2022
ел, 345-од номерлы
боерыгы редакциясендә)

# Индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга рөхсәт ителүе турында белдерү кәгазен җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми кагыйдәләр.

Индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга рөхсәт ителүе турында белдерү кәгазен җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты, региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда («Аеруча саклаулы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш), индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга рөхсәт ителүе турында белдерү кәгазен җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели» ( алга таба – Регламент, дәүләт хезмәте).

1.2. Гариза бирүчеләр: юридик һәм физик затлар.

Гариза бирүче исеменнән юридик затның җитәкчесе яисә аның шәхесен таныклый торган ышаныч һәм документлар нигезендә вәкаләтле зат килә.

1.3. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә профильләү (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү варианты, хезмәт күрсәтүче орган үткәрә торган анкеталау нәтиҗәсендә билгеләнгән тиешле билгеләре нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү) үткәрелми.

2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты.

2.1.Дәүләт хезмәтенең атамасы.

Индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга рөхсәт ителүе турында белдерү кәгазен җибәрү.

2.2. Башкарма хакимият органы исеме.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты ( алга таба – Комитет)

Дәүләт хезмәте Комитетның Биологик төрлелек бүлеге (алга таба - Бүлек) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе һәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба - КФҮ) аша күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза КФҮ аша бирелгән очракта, КФҮ дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлегенә ия.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

Индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга рөхсәт ителүе турында белдерү кәгазен җибәрү (әлеге Регламентка 1 нче кушымта) (алга таба-туры килү турында белдерү кәгазе);

Индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларга туры килмәү һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга рөхсәт ителмәү турында белдерү кәгазен җибәрү (әлеге Регламентка 2 нче кушымта) (алга таба-туры килмәү турында белдерү кәгазе);

Планлаштырыла торган төзү турындагы белдерү кәгазен карамыйча кире кайтару (әлеге Регламентка 3 нче кушымта)

туры килү (туры килмәү) турында белдерү кәгазенең дубликатын бирү;

туры килү (туры килмәү) турында белдерү кәгазенең дубликатын бирүдән баш тарту (әлеге Регламентка **3** нче кушымта).

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында шәхси кабинетына (http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба - Республика порталы) яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталына (http://gosuslugi.ru) (алга таба - Бердәм портал) имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Мөрәҗәгать итүче

тарафыннан башка мәгълүмат системаларында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу теркәлми.

Мөрәҗәгать итүчене сайлау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе шулай ук Комитетта яисә КФҮтә, мөһер һәм тиешенчә вәкаләтле вазыйфаи зат яисә КФҮ хезмәткәре имзасы белән расланган кәгазьдә басылган электрон документның нөсхәсе рәвешендә тапшырыла.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы

Туры килү (туры килмәү) турында белдерү кәгазен юллау процедурасын гамәлгә ашыру вакыты индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәр килгән көннән җиде эш көне тәшкил итә (алга таба - планлаштырыла торган төзелеш турында белдерү кәгазе).

Әгәр индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылса һәм планлаштырыла торган төзелеш турындагы белдерү кәгазендә индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү планлаштырыла торган типлаштырылган архитектура карарына күрсәтмә юк икән, Комитет:

1) ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон бәйләнешнең региональ системаларын кулланып, күрсәтелгән белдерү кәгазен һәм аңа кушып бирелгән тасвирламаны мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитетына җибәрә;

2) әлеге белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрларының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары һәм РФ ШтК тарафыннан билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә, һәм планлаштырыла торган төзелеш турында белдерү кергән көнгә гамәлдә булган башка федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килә торган документлар белән билгеләнгән һәм белдерү кәгазе кергән көнгә гамәлдә булган,рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларына туры килү-килмәүне, шулай ук җир кишәрлеген рөхсәт ителгән файдалану һәм Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм планлаштырыла торган төзелеш турында белдерү кәгазе кергән көнгә гамәлдә булган чикләүләр нигезендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге булуны тикшерә;

3) бу хәбәрнамә кергән көннән соң егерме эш көненнән дә соңга калмыйча, төзүчегә, аның тарафыннан планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү кәгазендә билгеләнгән ысул белән, РФ ШтК $51^1$ ст. 7 өлешенең 2 пунктында каралган, индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларын планлаштырыла торган төзү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларга туры килү турында һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру рөхсәт ителүе турында яки индивидуаль

торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларын планлаштырыла торган төзү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларга туры килмәве турында һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру рөхсәт ителмәве турында белдерү кәгазен җибәрә.

Белдерү кәгазен карамыйча кире кайтару-планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәр кергән көннән өч эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче КФҮкә мөрәҗәгать иткәндә гариза һәм кушып бирелә торган документларны Комитетка тапшыру, Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тәэмин ителә. Төзелеш тәмамлануы турында белдерү кәгазен җибәрү яки кире кайтару процедурасын гамәлгә ашыру вакытында, гаризаның КФҮтә булу вакыты һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен Комитеттан КФҮкә тапшыру вакыты кертелми.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны бирү мөрәҗәгать итүче килгән көндә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска, Республика порталындагы шәхси кабинетка) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә гариза һәм кушып бирелә торган документларны Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Комитетка тапшыру тәэмин ителә. Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объектын төзүгә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайтуга бәйле рәвештә, капиталь төзелеш объектын төзүгә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү) процедурасын гамәлгә ашыру вакытында КФҮтә булу вакыты һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен КФҮкә Комитеттан тапшыру вакыты кертелми.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны бирү мөрәҗәгать итүче килгән көндә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска, Республика порталындагы, Бердәм порталдагы шәхси кабинетка) җибәрү, дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Бердәм порталда, Республика порталында:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның карарларына һәм гамәлләренә

(гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрләр, эшчеләр.

2.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшыра торган дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1.Планлаштырыла торган төзелеш турында белдерү кәгазе (әлеге Регламентка 4 нче кушымта).

Планлаштырыла торган төзелеш турындагы белдерү кәгазенә кушымта итеп бирелә:

1) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән очракта, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар;

2) төзүче вәкиле тарафыннан планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе җибәрелгән очракта, төзүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ;

3) төзүче чит ил юридик заты булган очракта, чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы документларны рус теленә танылкланган тәрҗемәсе;

4) әгәр индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылса, РФ ГрК $51^1$ ст.5 өлешендә каралган очрактан тыш,индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы кыяфәтенең тасвирламасы. Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының тышкы кыяфәтен тасвирлау текст формасындагы тасвирламаны һәм график тасвирламаны үз эченә ала. Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының тышкы кыяфәтен тасвирлау текст формасында индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларына күрсәтмәне, аларның тышкы кыяфәтен төс ягыннан хәл итүне, индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының тышкы кыяфәтен билгеләүче төзелеш материалларын, шулай ук индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының, капиталь төзелеш объектының архитектур чишелешләренә карата таләпләр Шәһәр төзелеше Регламенты тарафыннан билгеләнгән, башка характеристикаларын тасвирлауны үз эченә ала. График тасвирлама индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының фасадын һәм конфигурациясен кертеп, тышкы кыяфәтенең сүрәтеннән гыйбарәт.

5) мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклаучы документ (шәхси мөрәҗәгать иткәндә). Республика порталы яки Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслаучы документтан мәгълүмат «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен электрон формада кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – ЕСИА) хисап язмасын раслаганда тикшерелә.;

6) мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ.

2. Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты төзелеше яисә аны реконструкцияләүнең планлаштырыла торган төзелеш яисә реконструкцияләү параметрлары үзгәргән очракта, төзүче индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү параметрларын үзгәртү турында белдерү кәгазе бирә (алга таба-параметрларны үзгәртү турында белдерү кәгазе) (әлеге Регламентка 5 нче кушымта).

Әгәр аның хокукы Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса, параметрларны үзгәртү турындагы белдерүгә җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар теркәлә.

Туры килү (туры килмәү) турында белдерү, планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәдә, параметрларны үзгәртү турында белдерүдә күрсәтелгән очракта, электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында бирелә.

Туры килү (туры килмәү) турында хәбәрнамәнең дубликатын бирү өчен мөрәҗәгать итүче Комитетка, әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасы нигезендәге форма буенча, туры килү (туры килмәү) турында белдерү дубликатын бирү турында язма гариза җибәрә.

Туры килү турында белдерү кәгазенең дубликатын бирү буенча, дәүләт хезмәте алу өчен, гариза бланкларын мөрәҗәгать итүче Комитетка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм кушылып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен кулланып җибәрелергә мөмкин:

1) Комитетка шәхсән яисә почта аша кәгазь иядә һәм «Электрон имза турында» 06.04.2011 ел, 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

2) КФҮ аша кәгазь иядә һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

Гариза биргәндә мөрәҗәгать итүчегә КФҮтән гариза җибәрелүен раслаучы теркәү номеры һәм электрон гариза бирү датасы белән расписка бирелә;

3) Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада.

Гаризаны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталының, Бердәм порталның шәхси кабинетында һәм электрон почта аша теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелеп, гаризаның җибәрелгәне турында белдермә килә.

Гариза һәм кирәкле документларны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә гариза гади электрон имза белән имзалана.

Мөрәҗәгать итүчегә, гади электрон имза алу өчен, «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» (алга таба - ЕСИА) федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алуны стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гариза һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Запросны республика порталы аша биргәндә гариза бирүче документларның электрон рәвешләрен яисә 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп, мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган документларны электрон рәвештә тапшыра.

Мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү «Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 141 статьясындагы 18 өлешендә каралган мәгълүмати технологияләр кулланып, Россия Федерациясе гражданы паспортын яисә шәхесне таныклаучы башка документны күрсәтү юлы белән яисә Комитетта, МФЦда мәгълүмати технологияләрне идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән шәхси кабул итү барышында гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар:

1) бу реестрда хокук теркәлгән очракта, җир кишәрлегенә Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә);

2) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылган очракта һәм планлаштырыла торган төзелеш турындагы белдерү кәгазендә типлаштырылган архитектура карарына күрсәтмә булмаса, планлаштырыла торган төзелеш турында белдерү кәгазе һәм аңа кушып бирелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы кыяфәтен тасвирлау (Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетында).

Әлеге Регламентның 2.6.1. пункты белән мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүче ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек ярдәмендә, гариза биргәндә мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныкланган электрон документлар рәвешендә алынырга мөмкин булган документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.

Гариза бирүче белән күрсәтелгән документларны тапшырмау, дүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) белдерү кәгазен (гаризаны)дәүләт хезмәте күрсәтү вәкаләтенә керми торган дәүләт хакимияте органына тапшыру;

2) белдерү кәгазе (гариза) формасында кырларны тулысынча тутырмау, шул исәптән Республика порталында, Бердәм порталда белдерү кәгазенең (гаризаның) интерактив рәвешендә;

3) тапшырылган документлар хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән вакытта үз көчләрен югалткан булса (шәхесне раслаучы документ; мөрәҗәгать итүче вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрен раслаучы документ);

4) кәгазьдә тапшырылган документа Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган төзәтмәләр булу;

5) электрон рәвештә бирелгән документларда, алар аркасында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган бозылган урыннар булу;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле белдерү кәгазе (гариза) һәм документлар, аларны бирү форматларына карата таләпләрне бозып, электрон формада бирелгән һәм (яки) укылмый торган булу;

7) 63-ФЗ номерлы Федераль законның 1[1] статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон култамганың чынлыгын тану шартларын үтәмәү ачыкланган очракта.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

1. туры килмәү турында белдерү кәгазе җибәрү өчен нигезләр:

а) индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрларының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары һәм РФ ШтК тарафыннан билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә, һәм планлаштырыла торган төзелеш турында белдерү кергән көнгә гамәлдә булган башка федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килә торган документлар белән билгеләнгән һәм белдерү кәгазе кергән көнгә гамәлдә булган,рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларына туры килмәве.

б) планлаштырыла торган төзелеш турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру, җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре һәм (яисә) Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм планлаштырыла торган төзелеш турында белдерү кәгазе кергән көнгә гамәлдә булган чикләүләр нигезендә рөхсәт ителми;

в) җир кишәрлегенә хокуклары булмау сәбәпле, төзүче булмаган зат тарафыннан планлаштырылган төзелеш турында бирелгән яисә җибәрелгән белдерү кәгазе;

г) РФ ШтК 51[1] статьясының 9 өлешендә күрсәтелгән срокта, Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетыннан индивидуаль

торак төзелеше объектының яисә бакча йортының тышкы кыяфәте тасвирламасының тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектларының шәһәр төзелеше регламенты белән федераль яки региональ әһәмияттәге территориаль зонага карата билгеләнгән архитектура карарларына туры килмәве турында хәбәр килү.

2. Белдерү кәгазен карамыйча кайтару өчен нигезләр:

а) планлаштырыла торган төзелеш турында белдерү кәгазендә түбәндәге белешмәләр булмаган очракта:

төзүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары (физик зат өчен);

төзүче (юридик зат өчен) атамасы һәм урнашу урыны, шулай ук юридик затның бердәм дәүләт регистрациясе турындагы язманың Дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең идентификация номеры, мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очрактан тыш;

җир кишәрлегенең кадастр номеры ( булганда), җир кишәрлегенең адресы яки тасвирламасы;

төзүченең җир кишәрлегенә хокукы турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлегенә башка затларның хокуклары турында белешмәләр (андый затлар булганда);

җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан (индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектыннан)рөхсәт ителгән файдалану рәвеше турында белешмәләр;

аларны төзү яки реконструкция ясау максаты белән, шул исәптән җир кишәрлеге чикләреннән чигенү турында, планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе бирелгән, индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган параметрлары турында белешмә;

шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты мөстәкыйль күчемсез милек объектларына бүлү өчен билгеләнмәгәнлеге турында мәгълүмат;

төзүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы;

төзүчегә белдерүләр җибәрү ысулы;

б) планлаштырыла торган төзелеш турындагы белдерүгә әлеге Регламентның 2.6.1. пунктында каралган документлар беркетелмәү.

Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән очракларда, планлаштырыла торган төзелеш турындагы белдерүдә һәм аңа кушып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла һәм белдерү җибәрелмәгән дип санала.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре

Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә

2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират

билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада да, запросны теркәү вакыты һәм тәртибе.

Гариза кергән көнне.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән соратып алу ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә.

Гариза бирүче яисә аның вәкиле тарафыннан КФҮ аша бирелгән гариза КФҮтән кергән көнне Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән соратып алу ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә.

Гариза бирүче яисә аның вәкиле тарафыннан КФҮ аша бирелгән гариза КФҮтән кергән көнне Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Республика порталына, Бердәм порталга электрон рәвештә кергән гариза, порталда запросларны автомат рәвештә теркәү булмаган очракта, Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү, шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә алып барыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм ярдәмче этләр белән йөрүчеләргә, бинадан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла, алар арасында:

бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү шартлары;

Комитет территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Комитет бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыга, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылуга ия булган инвалидларны озатып бару һәм аларга биналарда ярдәм күрсәтү;

инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, биналарга һәм хезмәт алуга тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешле урында урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны,

билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельеф-ноктал ы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертергә рөхсәт бирү;

ярдәмче этнең махсус укуын раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Ярдәмче этнең махсус укуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында»2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган форма һәм тәртиптә бирелә торган документ булган очракта, ярдәмче этне кертү рөхсәт ителә;

Комитет парковкасында I, II төркем инвалидлар йөртә торган транспорт чараларын бушлай кую өчен кимендә 10 процент урын (кимендә бер урын) һәм мондый инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны йөртүче транспорт чаралары бүлеп бирелә. Әлеге пунктта күрсәтелгән машина кую урыннарына, юл хәрәкәте кагыйдәләрендә каралган очраклардан тыш, башка транспорт чаралары куелырга тиеш түгел.

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан, инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алуга комачаулаучы киртәләрне үтәргә ярдәм итү.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең файдалану мөмкинлеге күрсәткечләре:

биналарның җәмәгать транспортына якын урнашуы;

кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Комитетның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;

документларны кабул итә торган бүлмәләргә инвалидларның керү мөмкинлеге булуы;

инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы башка киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

Комитет белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга карата прецедентларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Комитет белгечләре белән хезмәттәшлеге саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә, турыдан - турыикедән дә артырга тиеш түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар җибәргәндә, почта аша, шул исәптән электрон почта аша - бердән артырга тиеш түгел.

КФҮтә дәүләт хезмәте күрсәткәндә документларны кабул итү һәм бирү эшен КФҮ белгече башкара.

Мөрәҗәгать итүче КФҮкә мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны теркәгәннән соң, бер эш көне эчендә Комитетка гариза һәм документларны тапшыру тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Комитет һәм КФҮ арасындагы хезмәттәшлек килешү нигезендә, ә КФҮнең мөрәҗәгать итүчеләр арасында аралашу-КФҮ эше Регламенты белән җайга салына

Дәүләт хезмәте экстриториаль принцип буенча яки комплексы соратып алу составында күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Комитетта, Республика порталының шәхси кабинетында , КФҮтә алырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы күпфункцияле үзәкләрдә һәм электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзенчәлекләре.

2.14.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2.Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.3. КФҮтә дәүләт хезмәте күрсәткәндә документларны кабул итү һәм бирү эшен КФҮ белгече башкара.

Мөрәҗәгать итүче КФҮкә мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны теркәгәннән соң, бер эш көне эчендә Комитетка гариза һәм документларны тапшыру тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Комитет һәм КФҮ арасындагы хезмәттәшлек килешү нигезендә, ә КФҮнең мөрәҗәгать итүчеләр арасында аралашу-КФҮ эше Регламенты белән җайга салына

2.14.4. Гариза бирүче гаризаны электрон документ рәвешендә җибәрә ала, аны рәсмиләштерү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 7 июлендәге 553 нче номерлы «Дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны электрон документлар рәвешендә рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында» гы боерыгы белән билгеләнгән һәм ул гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән «Интернет» челтәреннән, Республика порталыннан яки Бердәм порталдан, шулай ук электрон рәвештә арадаш хәбәрләр һәм җаваплы мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итә, шул исәптән гади электрон имза кулланып, 63-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә тапшырыла.

Комитетка Региональ порталны яки Бердәм порталны кулланып, электрон документ рәвешендә кергән гаризаны теркәү, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә хәбәрнамәнең электрон формасында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Комитетка тапшыру датасын күрсәтеп, хәбәрнамәне формалаштыру һәм җибәрү, Комитетка гариза кергән көнне автомат рәвештә башкарыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү, аларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерү, аларны теркәү, карау, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында карар кабул итү, әлеге Регламентның 3.3 – 3.6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.14.6. Мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелә торган дәүләт хезмәте турында мәгълүматны Республика порталында, Бердәм порталда алу мөмкинлеге тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат мәгълүмати стендларда һәм Комитетның рәсми сайтында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) туры килү яисә туры килмәү турында Белдерү кәгазен җибәрү:

а) КФҮтән, Республика порталыннан, Бердәм порталдан, язма рәвештә Комитетка мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә ojm@tatar.ru рәсми почтасына)алынган гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

б) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү;

в) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү;

г) мөрәҗәгать итүчегә туры килү яисә туры килмәү турында белдерү кәгазен бирү;

3) планлаштырылган төзелеш турындабелдерүне караусыз кире кайтару:

а) белдерүне (гаризаларны) һәм КФҮ, Республика порталыннан, Бердәм порталдан алынган документларны, Комитетка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән рәсми почтага электрон документ формасында) кабул итү һәм теркәү ojm@tatar.ru к;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү һәм планлаштырыла торган төзелеш турында белдерүне һәм гариза бирүчегә документларны карап тикшермичә генә кире кайтару;

4) техник хаталарны төзәтү:

а) техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү (әлеге Регламентка 7 нче кушымта);

б) туры килү (туры килмәү)турында яңадан рәсмиләштерелгән белдерүне әзерләү;

в) мөрәҗәгать итүчегә туры килү (туры килмәү) турында яңадан рәсмиләштерелгән белдерүне җибәрү;

5)туры килү (туры килмәү) турында белдерүнең дубликатын әзерләү, бирү яки бирүдән баш тарту.:

а) туры килү( туры килмәү) турындагы белдерүнең дубликатын бирү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү (тәңгәл килмәү);

б) туры килү (туры килмәү) турында белдерүнең дубликатын әзерләү яки туры килмәү турында белдерүнең дубликатын бирүдән баш тарту.;

в)мөрәҗәгать итүчегә туры килү (туры килмәү) турында белдерүнең дубликатын яки туры килү (туры килмәү) турында беллдерүнең дубликатын бирү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән хәбәрнамә төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Мөрәҗәгать итүче бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) почта аша (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә. Кирәк булганда, бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче Комитетка шәхсән, телефон һәм (яки) электрон документ рәвешендә электрон почта аша, (e-mail: ojm@tatar.ru), кәгазь иядә почта аша, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша (http://ojm.tatarstan.ru), дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен, шул исәптән гаризаны рәсмиләштерү өчен мөрәҗәгать итә..

Мөрәҗәгать итүче КФҮкә дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, бирелә торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка сораулар буенча мәгълүмат бирә һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче КФҮ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат ала ала. (http://mfc16.tatarstan.ru/)

Шулай ук мөрәҗәгать итүче Республика порталында, Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация алырга хокуклы.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

3.3. Туры килү турында белдерү яки туры килмәү турында белдерү җибәрү.

3.3.1. Планлаштырыла торган төзелеш турында белдерүне, параметрларны үзгәртү турында белдерүне кабул итү һәм теркәү.

1. Белдерү (гариза) Комитетка шәхсән, ышанычлы зат, почта, электрон почта, Республика порталы, Бердәм портал, КФҮ аша тапшырылырга мөмкин.

Белдерү (гариза) электрон рәвештә Республика порталы, Бердәм портал аша бирелгән очракта, гариза бирүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизацияне Республика порталында, Бердәм порталда уза;

Республика порталында, Бердәм порталда электрон белдерү (гариза) формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон белдерү (гариза) формасын тутыра;

документларны электрон формада яки электрон документлар үрнәкләрендә электрон гариза формасында беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле билге куя);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле билге куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (тиешле электрон гариза формасында төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаны җибәрү турында белдерү кәгазе ала.

КФҮ аша гариза биргәндә:

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гаризаны бирә һәм әлеге Регламентның 2.6.1. пункты нигезендә документларны КФҮкә тапшыра.

Гаризаны кабул итүче КФҮ хезмәткәре, КФҮ эше Регламентында каралган процедураларны башкара.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен киртәләр булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, КФҮ белгече кабул ителгән һәм теркәлгән документларны КФҮ эше Регламентында билгеләнгән тәртиптә Комитетка җибәрә. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Комитет һәм КФҮ арасында эш тәртибе хезмәттәшлек турында килешү, ә КФҮнең мөрәҗәгать итүчеләр-КФҮ эше Регламенты белән җайга салына.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. КФҮ аша гариза биргән очракта, әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар КФҮ эше регламентында һәм КФҮ белән Комитет арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән белдерү (гариза) яки документларны кабул итүдән баш тарту.

2. Бүлек белгече:

гаризаны кабул итә һәм терки;

кергән документларны, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон формада һәм электрон рәвештә бирелгән документларны өйрәнә;

электрон документларның комплектлылыгын, укылуын тикшерә;

Республика порталына, Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән электрон култамганың чынбарлык шартларын үтәүне тикшерә (мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган очракта).;

мөрәҗәгать итүче буларак килгән мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерә;

документларны кабул итү датасы һәм керү номеры турында билге куеп, гариза бирүчегә почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) гариза күчермәсен тапшыра (гаризаны почта аша биргәндә);

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Әлеге Регламентның 2.7. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны (белдерү кәгазен) теркәү өчен киртәләр булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрне аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Бүлек белгече объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турындагы гаризаларны теркәү журналына (алга таба - Журнал) мәгълүмат кертә.

Журналда түбәндәгеләр күрсәтелә:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшыру датасы (Комитетка керү датасы);

мөрәҗәгать итүченең исеме;

документларны кабул иткән вәкаләтле структур бүлекчәнең вазыйфаи затының фамилиясе һәм инициаллары;

объектның исеме һәм кергән документларның саны (папкалар, тартмалар һ.б.);

мөрәҗәгать итүчегә туры килү (туры килмәү) турында турындагы белдерүне яки планлаштырыла торган төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту бирү датасы (почта юлламасы датасы);

Журнал әлеге Регламентка 8 нче кушымта нигезендә кулдан һәм электрон формада алып барыла.

Әлеге Регламентта күрсәтелгән процедураны үтәү техник мөмкинлек булганда, дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Комитетта гаризаны һәм

документларны теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кабул ителгән һәм теркәлгән документлар яки документлар кабул итүдән баш тарту турында белдерү проекты.

3.3.2. Ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

Әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документлар тапшырылган очракта, Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарга, дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарга, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, ведомствоара электрон хезмәттәшлек барышында катнашучы башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә белешмәләр алу өчен запрослар җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуны формалаштыру һәм җибәрү.

2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән запрослар нигезендә белешмәләр китерүчеләр белгечләре соратылган документларны (мәгълүматны) тапшыра яисә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында белдерү кәгазе җибәрә.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы органнар законнарда билгеләнгән срокта шушы Регламентның 2.6.2 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән мәгълүмат булмау турындагы запросларга яисә белдерү кәгазенә җаваплар.

3.3.3. Туры килү ( туры килмәү) турында белдерү кәгазен әзерләү.

Бүлек белгече:

шушы Регламентның 2.6.1 пункты таләпләренә туры килү-килмәү предметына документларны тикшерә;

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, әлеге Регламентта каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: каралган гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документлар.

2. Бүлек белгече кергән документлар нигезендә мөрәҗәгать итүчедән һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалардан:

туры килү (туры килмәү) турында белдерү әзерли. Туры килмәү турында белдерү әлеге Регламентның 2.8 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда әзерләнә;

туры килү (туры килмәү) турында белдерүне Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, әлеге Регламентта

каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, әгәр индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылса һәм планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә типлаштырылган архитектура карарына күрсәтмә кертелмәсә, төзелеш турында белдерү кергән көннән алып унҗиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Гариза һәм документларны электрон рәвештә Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта һәм шул ук вакытта гаризада дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү нәтиҗәсен алу күрсәтелсә, бүлек белгече законнар белән билгеләнгән форма буенча тәңгәл килмәү турында белдерү әзерли.

Процедураларның нәтиҗәсе: туры килү (туры килмәү) турында Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән белдерү.

3. Кисәтүләр булмаганда (туры килмәү), Бүлек башлыгы аны Комитет рәисенә килештерүгә һәм имзаларга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, әлеге Регламентта каралган алдагы процедураны тәмамлаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комитет рәисенә туры килү (туры килмәү) турында белдерү кәгазенә кул куюга юнәлдерелгән

4. Искәрмәләр булмаган очракта, Комитет рәисе туры килү (туры килмәү) турында белдерүгә кул куя һәм аны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, әлеге Регламентта каралган алдагы процедураны тәмамлаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: туры килү (туры килмәү) турында имзаланган гариза.

5. Мөрәҗәгатькә карата кисәтүләр булган очракта, Комитет рәисе Бүлек белгеченә эшләп бетерү кирәклеге турында резолюция белән документларны кире кайтара.

Туры килү (туры килмәү) турында эшләп бетерелгән белдерү Бүлек белгече тарафыннан Комитет рәисенә тапшырыла.

Комитет рәисе туры килү (туры килмәү) турында белдерүгә кул куя һәм аны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, әлеге пунктның 3 пунктчасында каралган процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: туры килү (туры килмәү) турында имзаланган гариза.

3.3.4. Туры килү (туры килмәү) турында белдерү җибәрү.

1. Бүлек белгече бирелгән гаризаларның туры килү (туры килмәү) реестрында туры килү турында белдерүне терки һәм гариза бирүчегә хат җибәрә.

Туры килү (туры килмәү) турында бирелгән белдерү Реестры әлеге Регламентка 9 нчы кушымта нигезендә кулъязма һәм электрон рәвешләрдә алып барыла

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Комитет рәисе тарафыннан туры килү (туры килмәү) турында белдерүгә кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: туры килү (туры килмәү) реестрында теркәлгән туры килү (туры килмәү) турында белдерү.

